# Мубаракшина Халидә апа сөйләгәннәрдән (1941 елда туган)



Пионерлыкның тискәре ягын белмим, хәтерләмим. Балаларны тәрбияләүдә бу оешманың өлеше зур булган дип уйлыйм. Өлкән кешеләрнең кайсыннан сорасаң да, минемчә, тәнкыйтьләмәсләр. Сугыштан соңгы авыр елларда ул балалар тормышына бер ямь, җылылык кертә, бердәмлек, дуслык хисе уята иде. Сборлар, артта калган укучыларга ярдәм итү, өмәләргә йөрү, урак өстендә ярыша-ярыша башак җыю, утауга йөрү, өлкәннәргә, мохтаҗ картларга булышу, авыруларга ярдәм күрсәтү, концертларда, мәктәптә кичәләрдә катнашу һ.б. Болар барысы да мораль канәгатьлек хисе тудыра иде. Һәр буынның үзенә генә хас үзенчәлекләре була инде. Менә безнең буынның балачагы пионерия белән бәйле.

Урманасты Шынталы